| СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«27» октябрь 2023 ел № 91

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Яңгул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл жирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге территориясендә үзара салым җыю һәм гражданнарның үзара салымы тәртибе турындагы нигезләмәгә Яңгул авыл жирлеге Советының 11.04.2014 елгы № 91 нче карары белән расланган (14.11.2017 ел, №56, 16.12.2019 ел, №116 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: "Җирле референдумда кабул ителгән карар нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, 18 яшькә җиткән барлык гражданнарга да үзара салым акчаларын түләүне өч ай эчендэ башкарырга, яшәү урыны җирлек чикләрендә булган, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, үзара салым суммасының 90 проценты күләмендә ташлама билгеләнгән: I группа инвалидлардан, аз керемле ялгыз өлкән пенсионерлардан (80 яшьтән өлкәннәргә), яман шеш авыруы белән авыртучылардан, армия сафларында хемәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан, Россия Федерациясенең Кораллы көчләренә 2023 елдан хезмәт итү өчен контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, җирлек башкарма комитетының хәбәрнамәсе нигезендә җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын, шулай ук түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә ала.

2. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итү baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Габдрахманов